**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ АКТАНЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

пр. Ленина, дом 17, с.Актаныш, 423740

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

Ленин пр.,17 йорт, Актаныш ав., 423740

Тел. (85552) 3-44-22, факс (85552) 3-44-14, E-mail: mail.Aktanish@tatar.ru , www.aktanysh.tatarstan.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ　　　　　　　　　　　　　　　　　　　　　　　　КАРАР

_____________　　　　ПР-89 15.04.2025　　　　　　　　　　№ ___

«Актаныш муниципаль районының муниципаль белем бирү оешмаларында төп гомуми белем бирү программалары буенча һәркем өчен мөмкин булган һәм түләүсез мәктәпкәчә, башлангыч гомуми, төп гомуми, урта гомуми белем бирүне оештыру турындагы нигезләмәне раслау хакында» Актаныш муниципаль районы Башкарма комитетының 2018 елның 13 сентябрендәге ПР-234 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

Норматив хокукый актларны гамәлдәге законнарга туры китерү максатларында, Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. «Актаныш муниципаль районы муниципаль белем бирү оешмаларында төп гомуми белем бирү программалары буенча һәркем өчен мөмкин булган һәм түләүсез мәктәпкәчә, башлангыч гомуми, төп гомуми, урта гомуми белем бирүне оештыру турындагы нигезләмәне раслау хакында» Актаныш муниципаль районы Башкарма комитетының 2018 елның 13 сентябрендәге ПР-234 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 3.1 пунктта «яисә тиешле белем бирү программасы буенча дәүләт аккредитациясенең гамәлдә булу срогы тәмамлану» сүзләрен, «дәүләт аккредитациясенең гамәлдә булуын туктатып тору» сүзләренә алмаштырырга, «дәүләт аккредитациясенең гамәлдә булуын тулысынча яисә аерым белем бирү дәрәҗәләренә карата туктатып тору» сүзләрен төшереп калдырырга;

1.2. 4.11 пунктта «мәктәпкәчә белем бирүнең тиешле үрнәк уку-укыту программаларын исәпкә алып» сүзләрен «мәктәпкәчә белем бирүнең тиешле федераль уку-укыту программасы» сүзләренә алмаштырырга, түбәндәге эчтәлекле җөмлә өстәргә: «мәгариф оешмалары тарафыннан эшләнгән уку-укыту программаларының эчтәлеге һәм планлаштырыла торган нәтиҗәләре мәктәпкәчә белем бирү федераль программасының тиешле эчтәлегеннән һәм планлаштырыла торган нәтиҗәләреннән түбәнрәк булмаска тиеш.»;

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүматы порталында (http:pravo.tatarstan.ru) һәм Актаныш муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга.

Башкарма комитет җитәкчесе　　　　　　　　　　　　　　　　　　　И.Ш.Бариев